

Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!
Сәлам, сәлам! Хәерле иртә!
Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!
Сау бул, дустым! Хәерле көн!

Сәлам, сәлам! Хәерле көн!
Сәлам, сәлам! Хәерле көн!
Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!
Сау бул, дустым! Хәерле кич!

Сәлам, сәлам! Хәерле кич!
Сәлам, сәлам! Хәерле кич!
Хәлләр ничек? Бик шәп, рәхмәт!
Сау бул, дустым! Тыныч йокы!

Тәмле төшләр! Тыныч йокы!
Тәмле төшләр! Тыныч йокы!
Сау бул, дустым! Тыныч йокы!
Сау бул, дустым! Тыныч йокы!












КОМБИНАТЫ
ЦИРК
РӘСЕМ СӘНГАТЕ МУЗЕЕ
МИЛЛИ ТЕАТР




## 3 Диалогны тыңла һәм сөйлә.


Төс
Сан
Уенчыклар
Мәктәп
Шәһәр

**2** **Тыңла һәм сорауларга җавап бир.** 5

Алсу кайда яши?
Шәһәрдә нәрсәләр бар?
Шәһәр нинди?
Авылда трамвайлар, троллейбуслар бармы?


ГАРРИ ПОТТЕР
ДӘВАМЫ
БЕЗДӘ ГЕНӘ!


— Мин . . . алам.






– Песи, песи, син кайда яшисең?
– Мин яшим авылда,
Әби белән бабайда.
Тәмле сөт эчәм, ак күмәч ашыйм.
Тамагым туйгач уйныйм һәм йоклыйм.

– Балык, балык, син кайда яшисең?
– Мин яшим елгада,
Зәп-зәңгәр чиста суда.
Салкын су эчәм, суүсем ашыйм.
Тамагым туйгач йөзәм һәм йоклыйм.

– Тиен, тиен, син кайда яшисең?
– Мин яшим урманда,
Иң биек агачта.
Тәмле су эчәм, чикләвек ашыйм.
Тамагым туйгач сикерәм, йоклыйм.